СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**01 ноябрь 2024 ел** **№10**

**Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Печмәнтау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Ташкичү авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Печмәнтау авылында Печмәнтау авылы, Җиңү урамы, 22 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 27 ноябренә 17 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ашытбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидларга, 75 яшьтән узган гражданнарга, көндезге формада белем алучы студентларга 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Җиңү урамы);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу, ут челтәрләрен төзекләндерү);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү (бензин белән эшли торган чапкыч сатып алу)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Печмәнтау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Печмәнтау авылы, Җиңү урамы, 22 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин

СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ